РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.01.2020 № 14-п

2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау Муниципаль программасын тормышка ашыруның Кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексын, “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында”гы 2013 елның 25 июнендәге №52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау Муниципаль программасын гамәлгә ашыруның Кыска вакытлы планына төзәтмәләр кертү белән бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 гыйнварындагы 76-п номерлы (2017 елның 9 октябрендәге 1287-п номерлы, 2018 елның 6 апрелендәге 373-п номерлы, 2009 елның 23 гыйнварындагы 55-п номерлы, 2009 елның 06 мартындагы 204-п номерлы) карары белән расланган, 2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау Муниципаль программасын тормышка ашыруның Кыска вакытлы планына үзгәрешләр кертергә һәм Кыска вакытлы планны яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карар кул куйган вакыттан үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б.Таиповка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
____________________
_____номерлы карарына
КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 27 гыйнварындагы
76-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 10 февралендәге 148-п номерлы карары белән расланган 2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау Муниципаль программасын тормышка ашыруның Кыска сроклы планы.

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган, 2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау Муниципаль программасын (алга таба - кыска вакытлы план, муниципаль программа) тормышка ашыруның әлеге Кыска вакытлы планы, Муниципаль программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү вакытын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча планлаштырылган хезмәт һәм (яисә) эш төрләрен аныклау, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү, муниципаль ярдәм күрсәтү төрләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, “Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында”гы 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон ), “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында”гы 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә эшләнгән.

## II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Саба муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын арттыру;

гражданнар өчен имин һәм уңайлы яшәү шартлары булдыру;

күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль ярдәм һәм дәүләт ярдәме күрсәтү.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

кыска вакытлы планны башкаручыларны сайлап алуның үтә күренмәле һәм ачык процедураларын эшләү һәм үтәү;

озак сроклы материалларны һәм ресурсларны саклау технологияләре ярдәмендә капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслыкны куллану.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру вакыты-2017, 2018, 2019 еллар.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 19,222 мең кв.метр булган 9 күпфатирлы йортта 845 гражданны имин һәм уңайлы яшәү шартлары белән тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге кыска вакытлы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр кыска вакытлы планга карата 1 кушымтада күрсәтелгән.

## III. Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге

Саба муниципаль районының кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге, мондый җирлекләр территориясендә :

а) Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгәнен;

б) Саба муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә муниципаль программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы (еллык) муниципаль планнары дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән расланганын һәм килештерелгәнен исәпкә алып формалаштырылды.

Кыска вакытлы планны тормышка ашыруда Шәмәрдән, Эзмә авыл җирлекләре һәм Саба шәһәр җирлеге катнаша.

## IV. **2017 елда** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре.

| Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | пог. м. | 1 310,3 |
| су белән тәэмин итү | пог. м. | 171,8 |
| су бүлү | пог. м. | 1 138,5 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | кв. метр | 167,0 |
| Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | кв. метр | 1 707,1 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | кв. метр | 1 696,5 |
| Салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборларын урнаштыру | данә | 1 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 4 467,8 |

**2018 елда** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре.

| Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | пог. м. | 474,0 |
| су белән тәэмин итү | пог. м. | 474,0 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | кв. метр | 990,0 |
| Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | кв. метр | 344,9 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | кв. метр | 1737,7 |
| Түбәләрне ремонтлау | кв. метр | 2805,8 |

**2019 елда** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре.

| Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр | Үлчәү берәмлеге | Эш күләме |
|---|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | кв. метр | 258,0 |
| Күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | кв. метр | 615,0 |
| Түбәләрне ремонтлау | кв. метр | 1039,36 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | кв. метр | 3 474,5 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 2 560,0 |

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре, кыска вакытлы планның, “Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган, 2017, 2018, 2019 елларда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау Региональ программасын тормышка ашыруның Кыска вакытлы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры” дигән 2 кушымтасында китерелгән.

## V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар һәм күпфатирлы йорттагы бина милекчеләренең акчалары тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме :

**- 2017 ел**: 11 858 245,76 сум, шул исәптән :

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 3 559 727,79 сум;

җирле бюджетлар акчалары-2 253 000,00 сум;

күпфатирлы йорттагы бина милекчеләренең акчалары-6 045 517,97 сум;

**- 2018 ел:** 11 187 457,43 сум, шул исәптән :

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 840 821,93 сум;

җирле бюджетлар акчалары-2 253 000,00 сум;

күпфатирлы йортта бина милекчеләренең акчалары-8 093 635,50 сум;

**- 2019 ел:** 13 185 626,66 сум, шул исәптән :

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 4 041 714,35 сум;

җирле бюджетлар акчалары-2 253 000,00 сум;

күпфатирлы йортта бина милекчеләренең акчаларын - 6 890 912,31 сум тәшкил итә.

**2017** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сум |
|---|---|
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, шул | 1 278 061,44 |
| су белән тәэмин итү | 243 857,24 |
| су бүлү | 1 034 204,20 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | 44 752,37 |
| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | 2 093 465,31 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 4 349 052,96 |
| Салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборларын | 48 338,00 |
| Подъездларны ремонтлау | 3 531 452,40 |
| Техник паспортлар әзерләү | 210 355,23 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 200 661,96 |
| Төзелеш контролен тормышка ашыру | 102 106,09 |
| Барлыгы | **11 858 245,76** |

**2018** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сум |
|---|---|
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән: | 397 385,13 |
| су белән тәэмин итү | 397 385,13 |
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | 404 429,56 |
| Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | 401 092,04 |

| | |
|---|---|
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 3 788 627,43 |
| Түбәләрне ремонтлау | 5 881 206,84 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 197 830,52 |
| Төзелеш контролен тормышка ашыру | 116 885,91 |
| Барлыгы | **11 187 457,43** |

**2019** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт
ясау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сум |
|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | 130 677,78 |
| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә караган подвал биналарын ремонтлау | 758 643,64 |
| Фасадны җылыту һәм ремонтлау | 7 624 332,42 |
| Түбәләрне ремонтлау | 2 286 136,85 |
| Подъездларны ремонтлау | 1 900 731,23 |
| Техник паспортлар әзерләү | 94 000,00 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 259 888,56 |
| Төзелеш контролен тормышка ашыру | 131 216,18 |
| Барлыгы | **13 185 626,66** |

Капиталь ремонт үткәрү бәясе күрсәтелгән күпфатирлы йортлар исемлеге кыска сроклы планга 3 кушымтада китерелгән.

VI. Кыска сроклы планны тормышка ашыру механизмы

Әлеге кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру Саба муниципаль районы Башкарма комитеты, ТМШ, идарә оешмалары, биналарның милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба – кыска сроклы планны үтәүчеләр) тарафыннан тормышка ашырыла.

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – министрлыкка) региональ программаны тормышка ашыру буенча кыска вакытлы муниципаль планнарны формалаштыра һәм җибәрә;

Министрлыкка норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы башка документлар тапшыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнаша;

капиталь ремонт эшләрен финанслауга исәпләнгән җирле бюджет акчаларын, Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә күчерә;

күп фатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау эшләре буенча техник заказчы функцияләрен региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын килештерә; күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчаларны куллану очракларыннан тыш;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп тора;

Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска сроклы планны гамәлгә ашыру максатларында, мәгълүматлар базасын булдыра һәм аның актуаль торышын тәэмин итә (шул исәптән, күпфатирлы йортларда торак һәм торак булмаган биналар мәйданнары буенча мәгълүматлар);

Фондка хисап формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны Министрлыкка һәм кыска вакытлы планның башка башкаручыларына тапшыра.

ТМШ, идарә оешмалары:

милекчеләргә ай саен капиталь ремонтка кертемнәр буенча түләүләр хисаплыйлар, бина милекчеләреннән капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә түләнә торган акчаларны җыялар, Региональ оператор счетында капиталь ремонт фонды формалашкан очракта, милекчеләрнең капиталь ремонт өчен кертемнәрен Региональ оператор счетына күчерәләр, һәр милекченең түләүләре турындагы мәгълүматны https://bars-monjf.tatarj-u/monjf/ web адресындагы капиталь ремонтның дәүләт программасын үтәүне формалаштыру һәм мониторинглауның, торак фонды объектлары торышын мониторинглауның интеграцияләнгән мәгълүмати-аналитик системасына бушаталар.;

милекчеләрнең капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча бурычлары барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар күрәләр;

тикшерү актлары, капиталь ремонт буенча эш күләменә дефект исемлекләре, башкарылган эшләр актлары килештерәләр;

региональ оператор белән, милекчеләрнең капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча түләү кәгазьләрен формалаштыру һәм ай саен түләүләрне хисаплау,акчаларның региональ оператор исәбенә кертүләрен тәэмин итү буенча, шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу белән проект документларын әзерләүне тәэмин итәләр;

Министрлык раслаган тәртип нигезендә сайлап алу оештыручысы булып торалар;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

торак милекчеләренә капиталь ремонт башлау вакыты, кирәкле эшләр исемлеге һәм күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йорттагы уртак милекне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында һәм Россия

Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тәкъдим итәләр;

күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча милекчеләрнең җыелышларын оештырылар;

капиталь ремонт объектларына керүне рөхсәт итәләр;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тоталар, шулай ук капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән,капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга алуда катнашалар;

күпфатирлы йортны авариясез эксплуатацияләүнең һәм аңа керүче инженерлык системаларының билгеләнгән гарантия срогыннан ким булмаган күләмдә капиталь ремонтлау буенча дефект исемлекләрен, проект-смета һәм башкарма документациясен саклыйлар.

Бина хуҗалары:

капиталь ремонт буенча эш күләменә тикшерү актлары, дефект исемлекләре килештерәләр;

күп фатирлы йортларда капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән аларны файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

кыска сроклы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән вакытта күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау эшләрен башкаруны тәэмин итәләр;

башкарылган эшләр актларын КС-2, КС-3 формасы буенча формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күп фатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплы;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешма:

проект документларын, шул исәптән сметаларны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәргәндә төзелеш контролен гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эш актларын килештерәләр;

объектны кулланышка кабул итүдә катнашалар, объектны кабул итү актын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплылык тоталар;

проект оешмасыннан проект-смета документларын кабул итәләр;

күпфатирлы йортта уртак милекне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне кабул итү актына кул кую көненнән соң 10 көн эчендә,әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче шәхескә, күпфатирлы йортта уртак милекне капиталь ремонтлау турында документларның күчермәләре (шул исәптән капиталь ремонт эшләрен башкару турында проект,смета документларының,хезмәтләр күрсәтү һәм капиталь ремонт буенча эшләрнең үтәлеше турында килешүләрнең күчермәләре) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документларның күчермәләрен тапшыралар;

техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

Район массакүләм мәгълүмат чаралары - «Саба таңнары» газетасы һәм«Саба дулкыннары» ТРК массакүләм мәгълүмат чараларында кыска вакытлы пландагы чараларны тормышка ашыру барышын даими яктыртып баралар.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «торак фонды мониторингы»бердәм мәгълүмат продуктында тормышка ашырыла.

## VII. Күпфатирлы йортларда уртак милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар, Министрлык тарафыннан расланган тәртип нигезендә, төбәк операторы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары, муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан сайлап алына.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов